АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**«23» 12. 2022 г.** **№ 73**

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән булган, дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-701 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указын башкарып,

БОЕРУ:

1. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән булган, дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат,

шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген расларга (алга таба – Исемлек).

2. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының хокук һәм кадрлар белән тәэмин итү бүлегенә:

2.1. Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә алар эштән киткәндә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясында каралган чикләүләрне, бурычларны һәм җаваплылыкны аңлатырга.

2.2. Әлеге боерыкны Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән булган, дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында» 31.01.2022 елдан № 6 боерыгы үз көчен югалткан дип таныргa.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче                                                                    Т.И. Миңнуллина

Татарстан Республикасының
инвестицион үсеш агентлыгының
«23» 12. 2023 № 73
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән булган, дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеге**

| № т/б | Вазыйфаның атамасы | Вазифалар саны |
|---|---|---|
| | Җитәкчелек | |
| 1 | Җитәкченең беренче урынбасары | 1 |
| 2 | Җитәкче урынбасары | 2 |
| | Инвестицион проектларны экспертиза бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 2 |
| | Инвестицион проектларны алып бару һәм аларга ярдәм итү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 1 |
| | Мәгълүмати-аналитик бүлек | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| | Дәүләт-хосусый партнерлыкны үстерү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 1 |
| 3 | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| | Хокук һәм кадрлар белән тәэмин итү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы киңәшче | 1 |
| | Финанс исәбе һәм дәүләт сатып алулары бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| 2 | Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| | Беркетмә бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | Инвестицияләр җәлеп итү эшчәнлеген координацияләү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | Инвестицион җәлеп итүчәнлекне үстерү һәм алга җибәрү бүлеге | |
| 1 | Бүлек башлыгы | 1 |
| | **Барлык:** | **22** |